وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт


**№26 (143). 29 июнь 2012 / 10-шәгъбан-1433**

**ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ**





Татарстан дин әһелләре Болгарда беренче утырышларын уздырды ▷ 2 ◁



Татар шәҗәрәләре тарихыннан ▷ 3 ◁




Дини белемне Татарстан мәдрәсәләрендә алыгыз! ▷ 4 ◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

**ГАЕТ КӨННӘРЕ ТӘГАЕНЛӘНДЕ**

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2012 елда Ураза һәм Корбан гаетләрен уздыру көннәрен билгеләү турындагы Указга кул куйды.**

Ай календаре һәм урнашкан традицияләр буенча 2012 елның 19 августы (якшәмбе) - Ураза гаетен, ә 2012 елның 25 октябре (пәнҗешәмбе) Корбан гаетен уздыру көннәре итеп билгеләнде.

**РИУДА КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ**

**27 июнь көнне Россия ислам университетында "Күпмилләтле һәм күпдинле мохиттә филология: торышы һәм перспективалар" дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Аны РИУның филология һәм илләрне өйрәнү кафедрасы оештырды.**

Җыенда катнашучыларны РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, әлеге вузның фән эшләре буенча проректоры Рөстәм Батыров, Фәлистыйннан, Йәмәннән, Сүриядән, Туністан килгән мәртәбәле кунаклар сәламләде.

Рәфыйк Мөхәммәтшин бу җыенның фәнни тәҗрибә уртаклашу максатыннан уздырылуын хәбәр итте. Рөстәм Батыров та мондый конференцияләр хезмәткәрләрнең фән һәм белем бирү юнәлешендә башкарган эшен бәяләргә мөмкинлек бирә, дип белдерде.

**ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ**

**27 июнь көнне Казан-Уфа юлы өстендә, Татарстанның Актаныш районына караган Пучы һәм Әнәк авыллары арасында, ямьле Ык елгасы ярларыннан ерак булмаган урында мосафирларга гыйбадәт кылыр өчен яңа мәчет ачылды. Изге йорт Җәлил бистәсендә туып-үскән "Протон" оешмасы генераль директоры Ренат Нуретдиновның иганә акчасына төзелде.**

Мәчетнең ачылу тантанасында Актаныш муниципаль районы башлыгы Энгель Фәттахов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, казыйлар, мөхтәсибләр, имам-хатыйбләр, киң җәмәгатьчелек катнашты.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең гомуми бүлек мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин сүзләренә караганда, мосафирларга намаз уку, гыйбадәт кылу өчен уңайлы булган мондый мәчетләр Казан-Чаллы юлы буенда (Мамадыш районында) моннан берничә ел элек салынган. Хәзерге вакытта Казан-Ульян юлы буенда да мондый изге йорт төзелеп килә.

**ЛАЕШ ИМАМНАРЫ ЛАГЕРЬЛАРДА ДӘРЕС БИРӘ**

**Лаеш мөхтәсибәте имамнары, башкалардан аермалы буларак, авыл мәктәпләре каршында оештырылган балалар лагерьларына да йөреп, дини сабак, әдәп-әхлак, тәрбия дәресләре бирә.**

Бүгенге көндә районның Үзәк мәчете каршында оештырылган лагерь да матур гына эшләп килә. Мөселман балалары әлеге лагерь кысаларында күңелле ял итү белән беррәттән, шәригать кануннары, башлангыч ислам гыйлемен дә үзләштерәләр.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# 3 ИЮЛЬ – БӘРАӘТ КИЧӘСЕ




**Бу кичә бик фазыйләтле һәм нурлы кичә булып санала. Галимнәр, бу кичәне гафләттә (ваемсыз), гыйбадәтсез үткәргән кешеләр нинди зур өстенлектән мәхрүм булганнарын белсәләр, үкенү күз яшьләрен түгүдән туктый алмаган булырлар иде, дип әйтәләр. Бәраәт көнен – уразада, төнен гыйбадәттә үткәрү, өч тапкыр "Йәсин" сүрәсен уку киңәш ителә. Бәраәт кичәсендә 3 "Йәсин" уку тәртибе:**

Беренче "Йәсин"не укыр алдыннан ният кылу рәвеше: "Раббым, дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булу өчен "Йәсин" укырга (укымакка) ният кылдым. Раббым, кабул итсәң иде". "Йәсин" сүрәсе укыла, аны тәмамлаганнан соң "Бәраәт" догасы укыла.

Икенче "Йәсин"не укыр алдыннан ният кылу рәвеше: "Раббым, дөньяда озын һәм гыйбадәтле гомер насыйп булсын өчен "Йәсин" укырга (укымакка) ният кылдым, Раббым, кабул итсәң иде". "Йәсин" сүрәсе укыла, аны тәмамлаганнан соң "Бәраәт" догасы укыла.

Өченче "Йәсин"не укыр алдыннан ният кылу тәртибе: "Раббым, мине, гаиләмне һәм якыннарымны бөтен начарлыклардан саклавыңа һәм ризыкларыбызны мул итүеңә өметләнеп, "Йәсин" укырга (укымакка) ният кылдым, Раббым, кабул итсәң иде". "Йәсин" сүрәсе укыла, аны тәмамлаганнан соң "Бәраәт" догасы укыла.

**"Бәраәт" догасы**

اِسْمِي كَتَبْتَ كُنْتَ اِنْ اَللّٰهُمَّ شَقِيًّا اِسْمِي كَتَبْتَ كُنْتَ اِنْ وَ السُّعَدَاءِ دِوَانِ فِي اكْتُبْ وَ فَامْحُهُ الْاَشْقِيَاءِ دِوَانِ فِي
الْكِتَابِ اُمُّ عِنْدَهُ وَ يُثْبِتُ وَ يَشَاءُ مَا اللّٰهُ يَمْحُ الْكَرِيمِ كِتَابِكَ فِي قُلْتَ فَاِنَّكَ فَاثْبِتْهُ السُّعَدَاءِ دِوَانِ فِي سَعِيدًا

***Аллаһуммә ин күнтә кәтәбтә исмии шәкыййән фии диүәәниль-әшкыййәи фәмхуһу үәктүб фии диүәәнис-сүгәдәә. Үә инкүнтә кәтәбтә исмии сәгиидән фии диүәәнис-сүгәдәәи фәсбүтһу фәиннәкә культә фии китәәбикәль-кәриим. Йәмхуллааһу мәә йәшәәү үәйүсбит үә гиндәһу уммуль-китәәб.***

Мәгънәсе: Йә Аллаһым, әгәр мине бәхетсез итеп, исемемне бәхетсезләр дәфтәренә язган булсаң, аны сөртеп юк итсәң иде һәм бәхетлеләр дәфтәренә язсаң иде. Әгәр мине бәхетлеләрдән итеп, исемемне бәхетлеләр дәфтәренә язган булсаң, әлеге язуны беркайчан да сөртелми торган ит. Чынлыкта, син Коръәни-Кәримеңдә: "Аллаһы Тәгалә нәрсәне теләсә, ләүһулмәхфуздән шуны сөртер, юк итәр, теләгәнен исә беркетер, сөртелмәс итәр", – дип әйтәсең.

# Бала тәрбиясе турында уйланулар

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү гәләә расүүлинә Мүхәммәдиү гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗемәгииин. Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмүгәләйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһү.**

Дөньяда материалистик караш киң таралып, матди кыйммәтләр генә бәяләнә башлау кешеләрнең рухи байлыкларга карата булган мөнәсәбәтен тискәре якка үзгәртте. Бүгенге белем бирү системасы да балаларны бу материаль дөньядан, үзенең нәфесен канәгатьләндерү өчен, төрле юллар белән матди байлык табарга өйрәтә. Шуның нәтиҗәсе буларак, күп кеше, нинди генә юллар белән булса да, башкаларга читенлек, авырлык тудырып, рәнҗетеп, үзенең нәфесен канәгатьләндерергә омтыла. Бер-береңә карата хөрмәт, ярдәмләшү кебек сыйфатлар үзара конкуренциягә һәм бер-береңне күрә алмауга әйләнә. Эчкерсез мөнәсәбәтләр юкка чыга. Дөньяны да, кешенең үзен дә материаль яктан гына танырга өйрәтү - бүгенге белем бирү системасының иң кимчелекле һәм зарарлы ягы.

Байлык туплап, яхшы өйләр салып, затлы машиналар алып биреп, баланы бәхетле итеп була, дип уйлаган әти-әни дә хаталы юлда. Андый фикерләр дә ялгыш тәрбия җимешләре. Күпме генә тырышсаң да, барыбер сиңа караганда күбрәк байлык калдыручы булачак. Әтиәнисен калдырган байлыгына карап кына бәяләргә өйрәнгән бала, аларны барыбер булдыксызлыкта гаепләячәк. Картаймыш көнеңдә үзең төзегән зур йортта үзеңә урын да калмаска мөмкин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгв): "Әтинең балага калдырган иң зур мирасы - яхшы тәрбия", - диде. Кызганыч, байлык артыннан куып, күп вакыт үзебезнең сәламәтлегебез турында да, балалар тәрбиясе турында да онытып җибәрәбез. Бернинди байлык белән дә сәламәтлекне кире кайтарып, баланың холкын үзгәртеп булмый. Ашау-эчү, күңел ачу өчен генә дөньяга килеп тә торасы юк. Адәм баласының максаты югарырак булырга тиеш.



Балаларыбыз белән күбрәк аралашып, аңлашып, үзара мәхәббәт тәрбияли алсак, алар байлыкка караганда әти-әнисен ярата төшәр иде. Җәмгыятебездә картлар йортларына да ихтыяҗ әзрәк булыр иде.

Бүген өч көнлек дөнья байлыгына шулкадәр бирелгәч, безнең намаз укырга да, әти-әни белән сөйләшеп утырырга да, балаларыбыз белән аралашып, аңлашып, бер-беребезне хөрмәт итеп яшәргә дә вакытыбыз юк. Балалар ни эшләсә эшләсен, тик безне дөнья куудан яки телевизор караудан гына аермасын.

Кем соң ул бала? Ул каян килгән? Бәлки бу сораулар сәер дә яңгырый торгандыр. Әмма бүген кечкенә баланы теләсә кем уйнап карый ала торган аңсыз курчак дип кабул итәбез.

Бала бит ул рух рәвешендә дөнья яратылганда ук яралтылган. Аллаһ хозурында фәрештәләр, җеннәр янында яшәгән. Җир тормышында яшәү өчен әтисендә орлык буларак барлыкка килгән. Ана карынында шул орлыктан материаль формада формалашкан. Әти кеше ничек яшәгән, нәрсә ашаган, нәрсә эчкән, шуның нәтиҗәсендә нинди орлык җитештергән, әлбәттә, балада бу чагылыш таба. Алабута орлыгыннан күпме генә тырышсаң да, бодай үстереп булмый. Шулай ук булачак әни кеше дә нинди тормыш алып бара, ничек яши, кияүгә чыккач нәрсәләр ашый, нинди киемнәр киеп йөри - болар берсе дә әһәмиятсез түгел. Чөнки баланың тәне

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## Корьән елына багышланган сайт эшли башлады

**Әлеге сайт мөһим дини төсмер алган ел вакыйгалары белән генә таныштырып калмыйча, халкыбыз тормышында Изге Китапның ролен күрсәтергә дә омтыла.**

Билгеле булганча, 2012 ел Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Корьән елы дип игълан ителде. Казан шәһәре үзенең басма Корьәне - "Казан басмасы" белән дөнья күләмендә мәшһүр. Татарстанда Корьән елы Изге Китап басыла башлауга 225 ел тулу уңаеннан уздырыла. www.godkorana.ru сайты мөһим дини төсмер алган ел вакыйгалары белән генә таныштырып калмыйча, халкыбыз тормышында Изге Китапның ролен күрсәтергә дә омтыла. Әлеге сайт беренче чиратта татар телендә ачыла һәм Изге Китап турындагы мәгълүматларны татарча тәкъдим итүгә өстенлек бирә.

Шулай ук сайтта Корьән тәфсирләре урнаштырылу динебезне пропагандалау, иманлы булырга өндәү булып тора. Озакламый Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Корьән елы кысаларында нәшер ителгән "Казан басмасы" электрон вариантта да эленәчәк. Танылган язучы Рабит Батулланың да тәфсирен биредә укып булачак.

# Кол Шәриф мәчетендә мөселман яшьләренең VI фестивале ачылды

**Татарстанда 25 июньнән алып 1 июльгә кадәр мөселман яшьләренең алтынчы фестивале уза. Аның тантаналы ачылышы Казанның Кол Шәриф мәчетендә үтте. Ачылышта ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Рафис Борһанов, Татарларның федераль милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе Илдар Гыйльметдинов, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз, "Идел" яшьләр үзәге, ТР Президентының Дини берләшмәләр белән элемтәләр идарәсе вәкилләре катнашты.**

Рафис Борһанов, җыенда катнашучыларны сәламләп, аларны форум узган көннәрдә генә түгел, ел әйләсендә бергәләп эшләргә, бер елдан соң нәтиҗәләр чыгарырга чакырды.

Илдар Гыйльметдинов исә: "Бүген башланган җыен сезнең өчен дә, безнең өчен дә әһәмиятле", - дип, биредә мөселман яшьләренең бер-берсе белән аралашудан туган фикерләрне урыннарда җиткерүләрен сорады. "Безнең төп бурычыбыз - әхлаклы яшьләр тәрбияләү. Әлеге эштә төп ярдәмчебез - дин. Дәүләт тә шушы юнәлештә эшләргә кирәклеген аңлый", - дип, ул форумның ял итү чарасы гына түгеллеген ассызыклап үтте.

Билгеле булганча, әлеге форум ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Татарларның федераль милли-мәдәни мөхтәрияте, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, "Идел" яшьләр үзәге, ТР Президентының Дини берләшмәләр белән элемтәләр идарәсе теләктәшлегендә оештырыла.

Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, фестивальне дәүләт дәрәҗәсендә оештыручыларга рәхмәт белдереп, яшьләргә Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре белән: "Йөрегез, аралашыгыз, сәламәт булырсыз", - дип мөрәҗәгать итте. Ул фикер алышуларның билгеле бер проектларга алып килү мөмкинлекләре барлыгын да белдерде.

Әлеге фестивальнең максаты - өммәт эчендәге проблемаларны хәл итү өчен, Россия Федерациясендә яшәүче мөселман яшьләрен берләштерү, алар арасында хезмәттәшлек урнаштыру, күптөрле проектларны тормышка ашыру, мөһим мәсьәләләрне хәл итү өчен, үзара эшлекле элемтәләрне җайга салу. Узган елдагы фестивальдә мөселман яшьләренең төбәкара берләшмәсен оештыру - моның ачык мисалы булып тора. Шулай ук бу фестиваль төбәкләрдәге лидерларны ачыкларга ярдәм итә. Алар урыннардагы үз оешмаларын оештырып җибәрә, фестивальгә охшаш чаралар үткәрә.

Билгеле булганча, мондый фестивальне уздыру идеясе Татар яшьләре көннәрендә барлыкка килгән. Мөселман яшьләре фестивале беренче тапкыр 2007 елда Татар яшьләре көннәре белән берлектә РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле аппараты ярдәме белән үткәрелгән. 2008 елдан алып мөстәкыйль оештырыла башлаган фестиваль берничә ел дәвамында Болгар шәһәрендә үткәрелде. Быел аны үткәрү урыны итеп Казаннан 30 чакрым ераклыкта урнашкан "Идел" яшьләр үзәге билгеләнде.

Елдан-ел фестивальдә катнашучыларның саны арта бара. Җитмеш кешедән башланган фестиваль быел 150 ләп кеше җыйды. Быел җыенга килергә теләп Иркутск, Кемерово, Мәскәү, Новосибирск, Пенза, Самара, Свердловск, Чиләбе өлкәләре, Башкортстан, Марий Эл, Мордовия, Чувашия, Удмуртия Республикалары, Түбән Новгород, Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Пермь крае, Татарстан районнары мөселманнары гариза бирде.

Әлеге мөселман яшьләре диспутларда, Россиянең яшь мөселманнарын борчыган актуаль мәсьәләләрне күтәрү өчен "түгәрәк өстәл" утырышларында, лекцияләрдә, семинарларда, бәйгеләрдә һәм Ислам буенча дәресләрдә катнаша. Шулай ук дин әһелләре белән очрашулар, экскурсияләр, фестивальнең көндәлек газетасын чыгару, биш вакыт намаз уку, мөселман фильмнарын күрсәтү каралган.

Быелгы чараларда Россиянең берничә төбәге мөфтиләре, аерым алганда, Мәскәү шәһәре мөфтие Әлбир Крганов, Пенза өлкәсе мөфтие урынбасары Хәмзә Еникиев, Ульяновск өлкәсе мөфтие Илдар Сафиуллин, Мордовия мөфтие Фәһим Шәфиев белән очрашулар көтелә. Шулай ук фестиваль чараларында Татарстанның дин әһелләре, галимнәр белән төрле темаларга очрашулар оештырылачак. Болар барысы да мөселманнарга үзләрен бердәм өммәт итеп хис итәргә, үзара фикер алышырга, уртак проблемаларны хәл итәргә, үсеш перспективаларын тикшерергә мөмкинлек бирә.

**www.tatar-inform.ru**

# Татарстан дин әһелләре Болгарда беренче утырышларын уздырды



**25 июнь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең ярты елга бер мәртәбә мөхтәсибләр, казыйлар, Голәмәләр шурасы әгъзалары, дини уку йортлары җитәкчеләре катнашында үтә торган пленум утырышы тәүге тапкыр Болгарның Ак мәчете резиденциясендә үтте.**

Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз 2012 елның беренче яртыеллыгында нәзарәт алып барган эшчәнлек турындагы чыгышында бу утырышның үзенә күрә бер тарихи төсмергә ия булуын билгеләп үтте. Беренчедән, чираттагы пленум утырышы Болгар җирендә нәзарәтнең рәсми җыелышларын үткәрүгә һәм Татарстан дин өлкәсе җитәкчеләренең бердәм булып киңәш-табыш кору өчен шушында җыелуына башлангыч булып тора. Икенчедән, Илдус хәзрәт сүзләре белән әйткәндә, "киләчәгебездә тәртип булсын, юлыбыз анык билгеләнсен өчен тарихка карап, тарихка таянып эшләргә кирәк".

Ул: "Башкарган эшләребезгә күз салып, киләчәккә планнарны билгеләргә дип җыелыштык. Бәрәкәт булыр дип, элек-электән Болгар җирлегендә дога кылганнар. Шулай ук Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтләре дә дога кылып китә торган булганнар. Ниндидер җитди эшләрне шушыннан башлаганнар", - диде һәм узган ярты ел дәвамында нәзарәт тарафыннан кылынган кайбер эшләрне санап үтте. Әйтик, иң зур уңышларның берсе булып нәзарәтнең мәдрәсәләргә дәүләт грантларын алырга булышуы тора. Грант инде ул шактый зур суммадагы акча. Мәдрәсә җитәкчеләре әйтүенә караганда, грант акчасына уку йортларына җиһазлар алганнар. "Кем акча түли - шул мәдрәсәләргә үзенең фикерен кертергә тели иде, моны таныргга кирәк. Уку-укытуга бик зур игътибар итү мөһим. РИУ безнең база һәм без аны башкаларга үрнәк итеп куябыз. Россиядә бердәнбер мөселман мәктәбебез - "Госмания" бар. Берничә мәчет кенә аңар ярдәм итә. Әмма безнең бит анда киләчәк кадрлар тәрбияләнә, аны да ташламаска кирәк", - диде ул. Шулай ук хәзрәт Корьән елы уңаеннан үткәрелгән Изге Китапны хәтем итү, Корьән сайтын булдыру, Изге Китапка багышланган "түгәрәк өстәл"ләр уздырылуына һәм "Казан басмасы"н нәшер итеп нигездә бушлай таратуга тукталып үтте. Моннан тыш нәзарәтнең үзенең ышанычлы хаҗ программасы булдыруын әйтте. Республика күләмендә мәчетләрдә йөзләгән җәйге мөселман балалар лагерьлары эшләп килүен искә төшерде.

Илдус хәзрәт чыгышыннан соң казыйлар, мөхтәсибләр сүз алды. Татарстаннаң баш казые Җәлил хәзрәт Рамазан аена кагылышлы сорауларга тукталды. Ул быел фитыр сәдакасен 50-300 сум итеп, зәкятне байлыгы ким дигәндә 130000 сум булганнарга тиешле дип тәкъдим итте. Башкалар казыйга каршы килмәде.

Шулай ук казый 19 июль көнне яңа ай туганын искә төшерде. Бу көнне кояш 21 сәгать 11 минутта байый һәм беренче тәравих намазы укыла. "Без, казыйлар, беренче тәравих намазын унтугызында сәгать ярым укырга дигән фикердә торабыз. 20 рәкагать укыла. Кайберәүләр: "Аны кыскартып булмыймы?" - дип сорый. Юк. Аны озынрак уку турында уйларга кирәк. Тәравих намазыннан кайткач сәхәр ашап ятып йокларлык кына булсын. 20 июльдә 4 сәгать 27 минутта кояш чыга. Сәхәрне кояш чыгарга 2 сәгать алдан ашап бетерү тиешле", - диде Җәлил хәзрәт.

Моннан тыш, дин әһелләре азан әйтү вакыты мәсьәләсен күтәрделәр. Чөнки республиканың көнчыгыш һәм көнбатыш районнары арасында кояш чыгу вакыты берникадәр аерыла. Мөфти көнчыгыш һәм көнбатыш районнары өчен намаз вакытлары аермасын төгәл билгеләргә кирәклеген әйтте һәм намаз вакытларын мәчетләргә язып кую мөһимлегенә басым ясады.

РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин: "Имамнарны җыеп укытабыз, әмма якшәмбе курсларында укытучылар да бик күп. Районнардан тәкъдимнәр булса остазлар җибәреп, урыннарда укыту мөмкин", - дип үз фикерен җиткерде.

Шулай ук утырышта соңгы айларда авыл муллаларын борчуга салган мәсьәлә - мәчетләрне газ белән тәэмин итүгә кагылышлы сорау күтәрелде. Кайбер районнарда газ оешмалары мәчетләрдән газга шәхси хуҗалыклар кебек түгел, рәсми оешмалар буларак түләүне таләп итә башлаган. Шул сәбәпле кайбер мәчетләр чыгымнарын каплый алмый. Бу уңайдан мөфти республика җитәкчелеге белән сөйләшүләр алып барылуын әйтте. Шулай ук ул мөхтәсибләрне транспорт белән тәэмин итү мәсьәләсе шактый күләмдә чишелүен һәм алга таба да аларны машиналы итүгә чаралар күреләчәген белдерде. Җыелышны йомгаклап: "Аллага шөкер, нинди генә хәлләр булса да шактый эш кылабыз, мөхтәсибләргә, ректорларга, Голәмәләр шурасына рәхмәтемне белдерәсем килә. Казан кайный. Менә шушы кайнап торган дини эшчәнлекне авылларга, Казаннан читкә дә таратырга кирәк", - дип, алга таба шәхсән авыллар буйлап йөрергә ниятләвен җиткерде.

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъват һәм мәгълүмат бүлеге***

# Бала тәрбиясе турында уйланулар

*(Дәвамы. Башы 1 нче биттә.)*

әни кеше ашаган ризыктан формалаша. Әти кеше аракы белән сугарып орлык җитештерсә, әни кеше хәрәм ризыклар ашап баланың тәнен үстерсә, ул бала туганда ук хәрәмгә, бозык эшкә хирыс булып дөньяга килә. 4 ай да 10 көндә шул формалашкан тәнгә Аллаһ хозурындагы җан иңә. Җан никадәр генә саф булмасын, аңа хәрәмнән хасил булган тән белән идарә итү авыр булачак. Инде баланың тәне дә, җаны да, аңы да бар. Әмма әле ул тагын 5 ай ана карынында кала, холык формалаша. Ана карынындагы баланың аңлаганын хәзер инде фән дә раслады. Бу вакытта булачак әти-әни нindирәк тормыш алып бара, үзара мөнәсәбәтләре нинди? Бигрәк тә әни кеше нинди фильмнар карый, тирә-юньдәгеләргә нинди сүзләр әйтә, берсе дә эзсез югалмый, баланың холкына тәэсир итә.

Шуңа күрә дә гаилә мәхәббәткә корылырга тиеш. Нәрсә соң ул мәхәббәт, ул каян килеп чыга? Ул кешеләрнең бер-берсенең матурлыгына сокланудан пәйда буламы? Әгәр матурлыкка гына корылган икән, тагын да чибәррәкне күргәч, юкка чыгарга яки үзгәрергә тиешме? Кеше үзе дә үзгәрми тормый. Картайган саен, яше барган саен үзгәрә, әлбәттә, матурлыкка таба түгел. Алайса, яшәгән саен мәхәббәт тә сүрелергә тиешме? Ә бәлки: "Мәхәббәт ул - ике тиленең өченчесен булдырырга омтылуы", - дигән кебек, җенси якынлыкка омтылумы? Алай булса, җенси тормыш та бит яшәгән саен сүрәнләнә, мәхәббәт тә сүнәргә тиешме?

Мәхәббәт ул әлеге сыйфатлардан өстен, ул - күңелләр аркылы җаннарның кавышуы, килешүе. Җаннар бер-берсе белән килешсә генә, мәхәббәт дәвамлы була, яшәгән саен көчәя һәм инде кешеләр бер-берсеннән башка яшәүне күз алдына да китерә алмыйлар. Бүген яшьләребез рухи якны уйламыйча, тышкы матурлыкка гына карап, "танцы, мансы, обжимансы" дигән кебек, кавышалар да, беренче авырлыктан ук мәхәббәт сабын куыгы кебек шартлый. Шул сәбәптән гаиләдә - еш кына аңлашылмаучылык, тавыш-гауга, үпкәләшүләр, аерылышулар, ятим һәм китек күңелле артык балалар.

*(Ахыры киләсе санда)*

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые**

# Татар шәҗәрәләре тарихыннан



**Татар халкының иң борынгы бабалары булarak мәгълүм булган һуннар, безнең эраның икенче гасырына кадәр кытай тарихчылары тарафыннан язып киленгән елъязмаларда "татарлар" дип аталганнар. Татар этнонимы безнең эрадан 1400 ел элек башланып безнең эраның 200 нче елларына кадәр Үзәк Азия далаларында үзенең бәйсезлеге өчен көрәш алып барган халыкның атамасы.**

Әлеге этноним хәтта төрек яки төрки дигән исемнән дә 1700 елга алдарак барлыкка килгән. Төрки/төрек этнонимы безнең эраның бишенче гасырына хәтле бөтенләй мәгълүм булмаган.

Һун каганнары дәүләт белән идарә итү процессында властьны бер-берсеннән нәсел кардәшлеге белән кабул иткәннәр, һәм шулай итеп безнең эрага кадәр үк нәсел шәҗәрәсе дигән төшенчә белән яхшы таныш булганнар.

Мәсәлән, Багадур каган безнең эрага кадәр 173 елдан алып 137 елга кадәр - 36 ел буена хакимлек иткән. Аннан соң тәхеткә Багадурның улы Каяк утырып, ул безнең эрага кадәр 162 елгача, ягъни үлеменә кадәр каган булып торган. Аның урынын, улы Куянҗын алып, ул безнең эрага кадәр 127 елгача хакимлек иткән. Куянҗының үз улы булса да, тәхеткә мәрхүм каганның энесе Ичизия утыра. Ичизия безнең эрага кадәр 114 елда үлгәч, тәхеткә аның улы Ачви утыра. Ачви безнең эрага кадәр 105 елда үлгәч, тәхеткә улы Чимсири утыра. Чимсири өч кенә ел идарә итеп 102 елда үлгән. Аның баласы бик яшь булу сәбәпле тәхеткә Ачывиның агасы Кулегу утыра (безнең эрадан элек 101 елда үлгән). Тәхет Кулегуның энесе Зютегуга кала. Ул биш ел идарә итеп безнең эрага кадәр 96 елда вафат булган. Татар тәхете Зютегуның улы Гюлюгуга кала һ. б.

Исемнәре саналган һун/татар каганнары безнең көннәрдән 2000-2200 еллар элек яшәсәләр дә, аларның кытай язмаларында сакланган шәхси исемнәре безнең замангача ирешкән татар шәҗәрәләрендәге борынгы исемнәргә уртаклыклар барын күрсәтәләр. Мәсәлән: Багадур - Баһадир, Куянҗын - Куянчы, Кулегу - Колык (Кулик), Зютегу, Гюлюгу - Гөләк, Ичизия - Уйазы һ. б. Китерелгән борынгы һун кеше исемнәрен чагыштыру материалы XVII-XX гасырлардан калган ташбилгеләрдәге, шәҗәрәләрдәге, топонимик һәм гидронимик сүзлекләрдәге текстлардан алынды.

Югарыда искә алынган һуннар/татарлар нигезендә безнең эраның IV-V гасырларында булачак төрки каганатның нигезен салган Ашина ыруы эшчәнлеге тарихи кытай язмаларында да искә алына башлый. Ашина ыруы тарихына бәйле шәҗәрә материалы да мәгълүм.

Кытай язма тарихи чыганакларында борынгы татарларның төрле кабиләләргә бүленеп яшәүләре хакында да хәбәрләр аз түгел.

Борынгы төрки каганаттан калган ташбилге текстларында, каганатлар составына катнашкан кавемнәр арасында "токуз татар", "утыз татар" кабилә берләшмәләре исемнәре 731 елда үлгән Кюль Тегин истәлегенә куелган ташбилге истәлеге текстында сакланып калган.

Татарлар турында XI гасыр төрки чыганагы Мәхмүд Кашгари сүзлеге һәм XII гасыр кытай чыганагы "Мэнда бэй-лу" китабы һәм башка язма чыганакларда искә алына. Кытай чыганагында татарларның кара, ак, кыргый татарларга бүленүләре турында да хәбәр ителә.

Фарсы тарихчысы Рәшидетдинең "Джами аттаварих" исемле XIII гасыр язма монгол чыганаклары буенча язган китабында 60 лап татар кабиләләренең исемнәре саналып үтелә. Алар арасында Алтын Урда дәүләтен төзүдә катнашкан - татар, меркит, боркыт, төмән, кирәйет, найман, кыбҗак, конгырат, барын, барлас һ. б. кабиләләрнең атамалары да бар.

Соңгы елларда татар нәсел шәҗәрәләрен туплау юлында эзләнүләр барышында безгә халкыбыз кулында сакланган - татар, боркыт, төмән, кирәйет, кыбчак, коңгырат, барлас, ширин нәселләренә караган язма үрнәкләрен табарга туры килде. Бу документлар татар халкының тарихын, безнең эрага кадәр яшәгән борынгы татарлар белән турыдан туры бәйле икәнен күрсәтәләр.

Бүгенге көнгә кадәр тупланган татар нәсел шәҗәрәләре язылган документларның саны биш йөзләп санала, ә кайбер язмаларда 50, 60 нәсел тарихларын теркәгәннәре дә бар. Шундыйлардан Олы Мәңгәр шәҗәрә китабында 56, Татар Танае, Яңа Тинчәле, Татар Өшегәне, Кече Сон, Иске Йәрмәк, Нократ Бәзәкә, Югары Чыршылы һ. б. авылларында 20 дән алып 60 ларга җиткән нәсел шәҗәрәләре җыентыклары мәгълүм.

Татар шәҗәрәләре кульъязмалары коллекциясе туплангач, алар нигезендә бу тарих чыганакларны фәнни һәм практик кыйммәте турында да фикер әйтергә мөмкинлек туды. Безнең тарафтан шәҗәрә язмалары тарихи һәм филологик чыганаклар буларак өйрәнелеп, алар буенча кандидатлык диссертациясе язылып якланды. 1995 елда татар шәҗәрәләре беренче мәртәбә җыентык рәвешендә тупланып, аерым китап рәвешендә бастырылды. Әлеге җыентыкта вариантлары белән 60 шәҗәрә тексты кульъязмалардан алып бастырылды.

1972 елдан башланган татар шәҗәрәләрен туплау әлегә кадәр дәвам итеп килә. Алар татар халкы яшәгән күп төбәкләрдән тупланып, халкыбызның этник тарихы буенча бай тарихи чыганаклар базасы тупланды. Алар нигезендә татар этнонимының безгә кушамат итеп тагылган сүз дип сөйләүчеләрнең ялган һәм дошманнар сүзен сөйләп йөрүләре күренә.

Татар шәҗәрә текстларын безгә кадәр татар галимнәреннән аеруча Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин бине Фәхреддин, Хөсәен Әмирхан, Һади Атласи кебек тарихчыларның хезмәтләрендә чыганаклар рәвешендә файдаланылганнар. Шулай ук аларның кульъязма архивларында да беркадәр сакланалар. Татар шәҗәрә текстлары XVII-XX гасыр татар ташбилгеләрендә дә теркәлә килгәннәр. Аерым кулларда да татар шәҗәрә текстлары саклана әле. Соңгы елларда халкыбызда шәҗәрә белән кызыксыну нык көчәйде. Аерым нәсел тарихлары калын китаплар рәвешендә язылып та басылып чыктылар.

Шәҗәрәләрне аерым предмет рәвешендә мәктәпләрдә укытулар турында хәбәрләр бар. Бу җәһәттән Казанда дәреслек-әсбаплар да басылып чыкканы мәгълүм.

Соңгы елларда үз нәселләренең тарихларын-шәҗәрәләрен төзергә теләүчеләрнең саны бик тиз арта бара. Әлбәттә, шактый гына урыннарда татар нәсел шәҗәрәләре текстлары сакланган. Алар ярдәмендә күп кенә кешеләр үзләренең нәсел шәҗәрәләрен яңарта һәм тулыландыра алалар. Әгәр инде кемнеңдер андый мөмкинлеге юк икән, ул эшне кеше, үзенең туганнарын барлаудан, нәсел таблицаларын төзеп бер-берсенә кардәшлек мөнәсәбәтләрен күрсәтүдән, аларның кайсы географик урыннарда (авыл, шәһәр, посёлок) туулары, яшәүләре, һөнәрләрен күрсәтүдән башлый алалар-.Үзләренең туганнары белән аралашкан күршеләре белән сөйләшүләр дә файдалы булыр. Мәрхүм туганнарының яшәү елларын зират ташларындагы язмалардан, архив (ЗАГС) белешмәләре аркылы да барлый ала. Инде моннан тыш архивларда Россиядә 1830 еллардан башланган метрика язмалары белешмәләре (архивларда саклана) аша 5-6 буын әби-бабалар турында мәгълүматлар табарга мөмкин. Архивлардан шулай ук Россиядә XVIII йөздән уздырыла килгән "ревизские сказки" документлары борынгы бабалар исемнәрен унлап буынга хәтле белергә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, әлбәттә, XVI-XVIII гасырларда патша хөкүмәте администрациясе тарафыннан алып барылган "писцовые книги", "перчневые и шежевые книги" һәм "оптовые документы" кебек архив чыганакларына да мөрәҗәгать итәргә була. Аларның китап булып басылганнары да мәгълүм.

Бу язмалар авторының 2002, 2009 елларда басылып чыккан ике томлык "Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы", 2010 елда басылган "Касимовские татары", 2012 елда басылган "Татар шәҗәрәләре. I том" китабы һәм башка дистәләрчә басмалардан да борынгы бабаларыгыз хакында мәгълүматлар табарга мөмкин.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ, филология фәннәре докторы**

# "Болгар-татар ташъязмалары" исемле "түгәрәк өстәл" узды

**21 июньдә "Иман" мәркәзе "Болгар-татар ташъязмалары" исемле темага багышланган "түгәрәк өстәл" оештырды. Бу чара кысаларында Нурулла Гарифның шул ук исемдәге китабы да тәкъдим ителде. "Түгәрәк өстәл"дә төп чыгышны профессор Фаяз Хуҗин ясады. Аның фикеренчә, эпиграфика татар тарихы өчен бик тә мөһим чыганак булып тора, чөнки татар тарихчылары язмалары сакланмаган, ә шушы кабер ташларыннан күп материал туплап була. Мәсәлән, кабер ташларында гарәп телендәге аять-хәдисләрдән кала бер өлеше татар телендә языла, димәк, филологлар ул текстларны өйрәнә алалар, ул гыйбарәләрдә күмелгән кешенең дәрәҗәсе, һөнәре дә язылырга мөмкин: бәк, морза, хан, ишан, алтын остасы һ. б. Бизәлешләре исә сәнгать өлкәсенә карый.**



Фаяз әфәнде Нурулла Гарифның шушы китапны чыгарып зур тырышлык куйганын ассызыклады. Тарихчы-галим Рәшит Галләм Нурулла Гарифның уникальлеген ассызыклады, чөнки ул - тарихчы һәм язучы, димәк язган әсәрләрендә тарихи дөреслекне бәян итә алырлык. Ул Нурулла әфәнденең тырышлыгы турында әйтте, чөнки шушы басылган китабы инде егерме тугызынчысы! Вәлиулла Якупов китапта чыккан мәгълүматны Татарстанның изге һәм истәлекле урыннарын билгеләү эшендә файдалы булуын әйтте, республикабызда дини туризм тармагын үстерергә кирәк, Нурулла Гариф тасвирлаган изгеләр каберләре киләчәктә зиярәт объектларына әйләнергә тиеш, әлбәттә.

Әле шушы елларда гына мәрхүм Туфан Миңнуллин инициативасы белән Зур Әтрәчтәге (Тәтеш районы) борынгы болгар каберстаны койма белән уратып алынды, анда ел саен зиярәтләр, ә быелдан башлап укулар да оештырыла. Шундый ук рәвештә башка каберләр янында да андый чаралар уздырылуы халкыбызны тарихына якынайтыр иде, бәрәкәтне хәятебезгә өстәр иде. Галимә Резеда Сафиуллина Нурулла Гариф хезмәтен РИУда дәрес үткәргәндә куллану тәҗрибәсе турында сөйләде, республикабызда эпиграфикага игътибарны күбрәк җәлеп итү кирәклеге турында да әйтте. Ахырда катнашучылар авторга иҗатында яңа уңышлар теләп калды.

# Күзләре күрмәүче ир өчпочмаклар пешереп сата

**Бу вакыйга 11 ел элек була. Җәйге кояшлы көндә Рөстәм бәрәңге кортларына агу сибәргә дип, бакчага килә. Эшкә тотына гына, басым югары булу сәбәпле баллон шартлый. Шартлау шул кадәр көчле була, хәтта Рөстәмнең теш казнасын һәм күзләрен бик нык җәрәхәтли. Бу мизгел аның бөтен тормышын үзгәртә. Бер минутка гына күзләрегезне бәйләп, Аллаһы Тәгалә биргән олы нигъмәтләрнең берсе - күрү сәләтен югалткан кеше нәрсәләр кичерүен тоеп карагыз, куркуга калырсыз.**

Әле бер ел элек кенә өйләнеп гаилә корган, җәмәгате белән бәхетле тормыш турында хыялланган Рөстәм менә шулай кинәт килеп чыккан фаҗига аркасында дөм сукыр кала. Бу вакыйгадан соң бер ай үткәч кызы Алия дөньяга килә. Рөстәм үзенең яраткан кызын, ярдәмчесен 11 ел инде күрми...

Рөстәм җомга һәм ял көннәреннән тыш һәркөн диярлек сәгать 11 дә 35 нче микрорайондагы "Час-Пик" кибете янына килә. Сәламәт, көчле, акыллы, ләкин күзләре күрми торган ир кеше гаиләсе өчен ни эшли ала соң? Гаиләсен һәм үзен туендыру өчен Рөстәмгә шактый кыенлыкларга җайлашырга туры килә. Ул пироглар, өчпочмаклар пешерергә өйрәнгән. Аларның пешкәнен таймер ярдәмендә белә. Продуктларны сатып алырга хатыны һәм кызы булыша. Кызы аңа кибеткә, кирәк җиренә барырга ярдәм итә. Алия әтисенең бармаклары тапсын өчен телефон төймәләренә кабарынкы наклейкалар ябыштырып куйган.

Инде менә 11 ел Рөстәм бөтен өметләрен-сабырлыгын җыеп Уфага танылган хирург-офтальмолог, профессор Эрнест Молдашев янына йөри. Ел саен бер-бер артлы күзендә җәрәхәтләрне төзәтәләр. Күз ясмыгы, төсле яры, мөгез катлау, күз карасы, челтәр катлау, склера - бу күз составының яртысы гына әле. Күз төзелешенең нинди катлаулы икәнен Рөстәм бик ачык аңлаган ир.

Быел операцияне аңар 28 майда ясарга тиешләр иде. Ләкин квотага акча бүлеп бирелмәү сәбәпле, операциясез калды, хөкүмәткә юкка өметләнгән. Узган елларда операциягә түләр өчен иганәчеләр таба иде.

Күрү сәләтен югалткач, дусты аны мәчеткә чакыра, Рөстәм барырга риза була. Шунда ул, әлхәмдүлилләһ, озак вакытлар эзләгән рухи таяныч таба. Һәркөн ислам фәннәре буенча нәрсәдер өйрәнүне максат итеп куя.

- Элек минем компьютерда "сөйли торган" клавиатура бар иде, ә хәзер андый программаны интернетта да табып булмый, - ди Рөстәм. (Әгәр дә бу программаның кайда барлыгын белсәгез, зинһар, Рөстәмгә шалтыратып әйтегез. Аның телефоны: 89196419727)

Квотага ышанып операциясез калуын, тагын бер ел үтеп китүен сөйләгәндә Рөстәм тавышында сагыш сизелеп тора.

... Аны әлеге сөйләшүдән соң бер атна үткәч, операциягә чакырдылар. Үз хисабына ясатырга. Акчасын гына тапсын...

***Ярдәм итәргә теләүчеләр түбәндәге реквизитлар буенча акча күчерә алалар:***

Расчетные счета:

**ИНН/КПП 1655068682 / 165501001**

**ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012**

**Р/с: 40703810400020000071 в ОАО "Ак Барс" банк г. Казань, ул. Декабристов, д. 1.**

**К/с: 30101810000000000805**

**БИК: 049205805**

**Назначение платежа: благотворительность (указать обязательно!)**

**Адрес: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.**

**Телефоннар: +7 (843) 236-46-32, 264-60-08.**

**Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.**

**Фондның сайты: www.закят.рф.**

**"Зәкят" хәйрия фонды**



# Дини белемне Татарстан мәдрәсәләрендә алыгыз!

**Күптән түгел генә "Дини белемне Татарстан мәдрәсәләрендә алыгыз!" исемле китап дөнья күрде. Бүгенге көндә андый белешмәнең чыгуы бик урынлы, чөнки мәктәпне тәмамлап чыгучы яшьләр кайсы уку йортына керергә дигән сайлау алдында тора.**




Ошбу җыентыкка исә Татарстанның бөтен мәдрәсәләре турында абитуриентларга адресланган мәгълүмат тупланган. Биредә түбәндәге мәдрәсәләргә керү шартлары турында белеп була: Казан "Мөхәммәдия" югары мөселман мәдрәсәсе, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе, Казан Ислам көллияте, Яр Чаллы шәһәренең "Ак мәчет" мөселман мәдрәсәсе, Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Әлмәт Ислам мәдрәсәсе, Буа мәдрәсәсе, Ибн Мәсгуд исемендәге Мамадыш мәдрәсәсе, Кукмара мөселман мәдрәсәсе, Түбән Кама шәһәренең "Рисалә" мөселман мәдрәсәсе, Урыссудагы "Фәнис" мәдрәсәсе. Әйтергә кирәк, шундый колачлы махсус җыентык Татарстан мөселман мәгариф системасында беренче тапкыр нәшер ителә. Китап Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнде. Китапта мәдрәсәләр тормышы белән бәйле булган фотолар да урын алды.

## *Бал кортының файдасы,*


### *яки Коръәндә алар турында нәрсә әйтелә?*

**"Нәхел (Бал кортлары)" сүрәсендә бал кортлары җыйган балның кешеләргә тәэсире турында бик күп аятьләр бар. Менә шуларның берсе (16 нчы сүрә, 69 нчы аять):**

Әгүзү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗииииим. Йәгъруҗү мим-бутууниһәә шәраабүм-мүхътәлифүн әлүәнүһүү фииһи шифәәәә ә үл-линнәәәс.



Аңлатмасы: "Бал кортлары кешеләр өчен эчләреннән төрле төстәге балларны чыгарып бирәләр, ул балларда ашар өчен тәме дә һәм кешеләр өчен шифасы да бар".



**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница - с 9:00 до 18:00, суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00, вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата. Тел. 297-28-90**

Реклама

## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 30.06.12 | 2:33 | 4:03 | 13:02 | 18:42 | 21:32 | 23:02 |
| Якшәмбе | 1.07.12 | 2:34 | 4:04 | 13:02 | 18:41 | 21:31 | 23:01 |
| Дүшәмбе | 2.07.12 | 2:34 | 4:04 | 13:02 | 18:41 | 21:31 | 23:01 |
| Сишәмбе | 3.07.12 | 2:35 | 4:05 | 13:02 | 18:41 | 21:30 | 23:00 |
| Чәршәмбе | 4.07.12 | 2:36 | 4:06 | 13:02 | 18:40 | 21:29 | 22:59 |
| Пәнҗешәмбе | 5.07.12 | 2:37 | 4:07 | 13:02 | 18:40 | 21:29 | 22:59 |
| Җомга | 6.07.12 | 2:38 | 4:08 | 13:02 | 18:39 | 21:28 | 22:58 |
| Шимбә | 7.07.12 | 2:39 | 4:09 | 13:02 | 18:39 | 21:27 | 22:57 |




**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №26 (143) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-538.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 28 июнь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**